СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 5-30 от « 17 » декабря 2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елның 26 июлендәге 2-9 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 20 декабрендәге 399-ФЗ номерлы Федераль законы һәм “Россия Федерациясендә Торак фондын хосусыйлаштыру турында” Россия Федерациясе Законының 16 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елның 26 июлендәге 2-9 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 5 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"- күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренә капиталь ремонт фондын формалаштыру ысуллары турында, капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау тәртибе турында хәбәр итү;

- күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда кичектергесез ихтыяҗ туганда җирле бюджет акчалары хисабына кире кайтарып һәм (яки) кире кайтарылмый торган нигездә өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибен һәм исемлеген раслау.”

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

000076